# Тема:

"Сөйләнмәгән хикәя"

Фатих Хөсни

# Максат:

- 1)Ф.Хөсни турында мини-белешмә бирү.” Сөйләнмәгән хикәя” әсәре белән таныштыру; укыла торган хикәя эчтәлегенә бәйләп, укучыларда әйткән сүзеңне үтәү турында дөрес күзаллау булдыру.
- 2)Бәйләнешле сөйләм,дөрес,йөгерек уку,иҗади фикерләү һәм үз фикереңне әйтеп бирә алу күнекмәләрен  үстерү.
- 3)Укучыларда әниләргә карата хөрмәт, кайгыртучанлык,әйткәнсүзләрен үтәү хисләре тәрбияләү.

# Җиһазлау:

- 1) Ф.Хөсни портреты
- 2)Слайд № 1 “Шигъри табышмак”
- 3) Слайд №2 ”Сүзлек эше”
- 4)Слайд №3 “Кагыйдәләр” 5)Слайд№4” Мәкальләр

# Материал:

- Уку китабы. 4 сыйныф
- Тест:”Әти-әниеңне тыңлыйсыңмы?”

# Дәрес тибы:

- Яңа материалны өйрәнү.

# Эш формалары:

- Фронталь,индивидуаль эш.

# Методлар:

- Әңгәмә, акыл штурмы.

# Дәрес барышы.

- 1.Дәресне оештыру.
- 2. Өй эшен кабатлау“Ике аяклы дусларыбыз” дигән темага язылган хикәяләрне укыту.
- 3. Яңа материалны өйрәнүгә кызыксыну тудыру.
- -Бүгенге дәресебезнең темасын ачыклау өчен,шушы шигъри табышмакны чишик.

- Слайд № 1

Мин аны бик сагындым,

- Күңелем әрни,уйлый әллә ни.
- Кем соң аны белми?
- Ул бит минем ...

- Молодцы,булдырдыгыз. Димәк,әни сүзе килеп чыкты. Сезнеңчә,кем соң ул әни?Ничек уйлыйсыз?
- -Җаваплар.
- -Бүген дәрестә әнине ярату,аның һәр әйткән сүзен тыңлау,аны бар нәрсәдән дә артыграк күрү,хөрмәт итүне үз эченә алган хикәя укырбыз.Ул әсәр "Сөйләнмәгән хикәя" дип аталачак.
- 4.Актуальләштерү.

- Слайд №2
- -Сүзлек эше.
- -баш ясау-ачыткы салынган камыр кую
- -киндерә-үрелгән нечкә бау
- -чат- монда:йортлары урамнар кисешкән урында урнашкан
- -нужа-ярлылык,фәкыйрьлек
- -аяк астына салып таптамау-тыңлау, игътибарсыз калдырмау.

- 5.Яңа материал өстендә эш.
- 1.Ф.Хөсни турында биографик белешмә бирү.Мини лекция
- 2.”Сөйләнмәгән хикәя” әсәрен уку.
- 1)Әсәрне уку үрнәген бирү(укытучы 1-2 абзацны укып күрсәтә)
- -укучылар эчтән укыйлар.
- (текст укылыр алдыннан укучылар алдына түбәндәге сорау куела:-Бу хикәя сездә нинди хисләр уятыр?
- 2)Хикәяне чылбыр тәртибендә укучылардан укыту
- 3)Сораулар өстендә эш
- А)Хикәядә кайсы чор сүрәтләнгән?
- -Элекке,байтак үткән еллар,авыр еллар чоры сүрәтләнгән.
- Б)Сездә нинди хисләр уянды?
- -Җаваплар.
- В)Хикәянең темасы кем язмышында чагылган?
- Тема- хикәядә сүз кем яки нәрсә турында бара.
- -Биктимер һәм аның әнисе турында.
- -дәреслек,98 биттәге сораулар өстендә эшне дәвам итү-№1,2,3.
- 6.Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.
- 1 Хикәянең төп фикерен әйтегез.
- Төп фикер-язучы бу хикәядә нәрсә әйтергә тели.
- Җавап бирә башлаганчы ,кагыйдәләр искә төшерелә.

Слайд №3

- -Үз фикереңне курыкмыйча әйт,
- -Башкаларны тыңла,
- -Кабатлама,төрле яклап фикер йөрт,

- Акыл штурмы:(уйларга 1 минут вакыт бирелә)
- Ә хәзер җавапларыгызны чират буенча әйтерсез.
- -Җаваплар тыңлана,нәтиҗә чсала.
- 1)Биктимер шушы вакыйгадан соң һичкайчан анасының сүзен аяк астына салып таптамаган.
- 2)Ә сезнеңчә әйткән сүзне тыңлау нәрсә ул?
-     2.  1 нче дәрәҗәдәге карточка.
- -Хикәядәге кайсы җөмләләр  96 нчы биттәге рәсем эчтәлегенә туры килә?
-             2 нче дәрәҗәдәге карточка.
- -Кайсы мәкальләр хикәя эчтәлеген ачарга ярдәм итәр?

- Слайд №4
- 1)Ана күңеле-балада,
- Баланыкы-далада.
- 2)Ата-ана хакын хакла,тел тидермә
- Тыңлаучан бул,каршы әйтеп,җан көйдермә!
- 3)Әйткән сүз-каккан кадак

- 3 нче дәрәҗәдәге карточка.
- -Хикәя эчтәлегенә туры килә торган 2 мәкаль уйла.
- Мәсәлән: Сүз бирдеңме-үтә.
- 4-Син хикәя ничек тәмамланыр дип уйлаган идең?
- -Вакыйгалар башкача да булырга мөмкин идеме?
- -Хикәядәге кебек хәлләр синең белән дә булганы бармы?

- Син үзең әти-әниеңне тыңлыйсыңмы?
- Ә хәзер җавабыгызның дөреслеген тикшереп карыйк. Тест: “Әти-әниеңне тыңлыйсыңмы?”
- (`һәр укучыга аерым биткә язылган тест таратыла)

- 5.Укылган хикәяне туган төбәк белән бәйләү.
- -Бу хикәядә авыр чор,ярлылык,фәкыйрьлек белән үткән язмыш чагылдырылган.Ә бүгенге тыныч тормышта да шушындый авыр хәлләргә очрарга мөмкинме?Сез нинди мисаллар китерә аласыз?

  -Әниләрне рәнҗетү.

  -Картлар йортларына бирү.һ б.

- 6.Йомгаклау
- Бүгенге дәресебезне “Әхлак кагыйдәләре” белән төгәллисем килә.

Очрашканда исәнләш син-телең калмас,
Сәламеңне алмаса тик надан алмас.
Ата-ана хакын хакла-тел тидермә,
Тыңлаучан бу,каршы әйтеп,җан көйдермә.
Укуың да,тәртибең дә булса үрнәк-
Үзеңә дә бик тиз килер кадер –хөрмәт.

- 7. Өй эше
- ! Хикәя эчтәлеген сөйләргә.
- 2.Иҗади эш:хикәяне дәвам итеп язарга